| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2018 ел № 22/5

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә теркәү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү турында

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ санлы Федераль законның 27 маддәсе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 2010 елның 17 февралендәге 192/1337-5 санлы карары белән расланган муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссиясен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру турындагы методик күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 2012 елның 05 декабрендәге 152/1137-6 санлы карарының 2.1 бүлеге белән расланган участок сайлау комиссияләре составлары резервын фомалаштыру Тәртибе, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2017 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә сайлау комиссияләре резервына өстәмә теркәү өчен кандидатуралар турында тәкъдимнәр җыю хакында» 10/74 санлы карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары территориаль сайлау комиссияләренә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәр участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә теркәү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәрне 1-3 кушымтага нигезләнеп кертергә.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары территориаль сайлау комиссияләренә җибәрергә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев